Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Глава Ижевского сельского поселения
423647, Менделеевский район
с. Ижевка, ул. Советская, д. 25
тел. 8(85549) 3-67-89

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Ижевка авыл жерлеге башкарма
Менделеевск районы
Ижевка авылы Совет урамы, 25
тел. 8(85549) 3-67-89

---

**КАРАР**

**12.11.2024 ел** **№ 2**

Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлегенең
Ижевка авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 22 ноябре 15.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздырырга.
2. 2024 елның 22 ноябре 16.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздырырга.
3. Гражданнар җыенының барлык этапларын уздыру урыны итеп Ижевка авылы Совет урамы, 26 й. адресы буенча Ижевка авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Ижевка авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

**Беренче этап**: Урман ур., Болын ур., Яшьләр ур., Курорт ур., Кояшлы ур., Яңа завод тыкрыгы, , Чәчәкле тыкрык , Яңа завод ур., Юбилей ур., 1 й.

**Икенче этап**: Яр Буе ур., Ветераннар ур., Яшел ур., Совет ур., Кыр ур., Татар ур., Курорт тыкрыгы, Мәктәп тыкрыгы, Ветераннар тыкрыгы, Яшьләр тыкрыгы, Юбилей ур, 2,3 й.

1. «2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, карамагында 18 яшькә кадәрге балалары булган аз керемле гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылганнардан бер тапкыр бирелә торган түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга.

“1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту , җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу һәм тигезләү, Курорт тыкрыгы, Курорт урамы, Кыр урамы буенча чишмәгә таба, килешү буенча түләү

2) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктыртуның энергияне саклый торган яктырткычларын сатып алу һәм алмаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, генератор сатып алу).

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, ягулык-майлау материаллары һәм килешү буенча хезмәт өчен түләү, карны чистарту, сәхнә түбәсенә каркас-тент сатып алу һәм урнаштыру) .

4) су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау ( суга батыру насослары сатып алу , Юбилей ур., 2 йорт буенча канализация торбасын алыштыру, суга батыру өчен фикаль насос сатып алу)”

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Ижевка авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Ижевка авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Мәсәгутова